**Галиева (Яруллина)Шәһидә сөйли:** (1927 нче елда туган)

Урманасты Шынталысы

«3 нче сыйныфта укыганда пионер булдым. Галстукларыбыз кызыл материядән иде. Пионерга керү зур тантана, бәйрәм булды. Галстукларны җәй көне дә салмадык. Авылда наданлыкны бетерүгә катнаштык, зурларны укыттык.

Аннан соң менә нәрсә хәтеремдә калган. Ударник булган өчен 3 класста 3м ситса белән бүләкләделәр. Вәлиев Шәүкәт һәм мин укытучыбыз Камалова Саимә апа белән яхшы укыган өчен Александровка авылы янындагы лагерьга ял итәргә бардык. Ул пионервожатый булып барды. Лагерьда балалар яңа уку елына көч җыйдылар. Балалар да, ата-аналар да бик канәгать булдылар.  Шул елларда авылга беренче машина кайтты.Пионерлар байраклар, быргы, барабаннар белән урамны шаулатып йөрделәр. яхшы укучыларны утыртып урам әйләндерделәр.М. Наил, М. Зәкия, В. Рәшидәләр дә яхшы укыйлар иде.”

Күңелендә уелып калган хатирәләрдә Шәһидә апа ул елларны бик еш искә ала. Хәзерге чор балаларга бик яхшы булуын искәртә. Бары тик аларга шәфкатьлелек, миһербанлылык хисләрен җуймаска киңәш итә.Дөньялар тыныч, имин булуын теләп кала.